**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**6 нчы август, 2024 ел** **№37-06**

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» МКУ, «Мәгариф идарәсе» МКУ, «Финанс-бюджет палатасы» МКУ,«Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ, Советы, Башкарма комитетның муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында Нигезләмә хакында»гы Актаныш муниципаль район Советының 2023 елның 10 февралендәге 27-04 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның эшчәнлеген стимуллаштыру тәртибен камилләштерү максатларында, Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» МКУ, «Мәгариф идарәсе» МКУ, «Финанс-бюджет палатасы» МКУ,«Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ, Башкарма комитетның, муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында Нигезләмә хакында»гы (Актаныш муниципаль районы Советының 2023 елның 15 декабрендәге 33-06 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Актаныш муниципаль район Советының 2023 елның 10 февралендәге 27-04 номерлы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» МКУ, «Мәгариф идарәсе» МКУ, «Финанс-бюджет палатасы» МКУ, «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ, Башкарма комитетның, муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында Нигезләмәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләү түбәндәгечә билгеләнә:

- муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары вазыйфаи окладка карата 100 проценттан артмаган күләмдә;
- муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары вазыйфаи окладка карата 80 проценттан артмаган күләмдә.
- муниципаль хезмәтнең әйдәүче, өлкән һәм кече вазыйфалары вазыйфаи окладка карата 60 проценттан артмаган күләмдә.

Катлаулылык һәм эшнең киеренкелеге өчен түләү билгеләү турындагы карар структур бүлекчә җитәкчесе тәкъдиме буенча эш бирүче тарафыннан кабул ителә.

Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар өчен эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык түләү 2023 елның 10 февралендәге 27-03 номерлы «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисләренә, аудиторларына, муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт

өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмә» нигезендә билгеләнә торган акчалата түләүнең 100 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.

Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар өчен эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен түләү билгеләү турындагы карар Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларны һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен премия бирү турындагы нигезләмәнең 5 бүлеге нигезендә эш итүче комиссия тарафыннан кабул ителә.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлегенә «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Актаныш муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә һәм 01.08.2024 елдан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет рәисе** **Л.Р.Зарипов**